МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.11.2021 г.Казань № 849

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 8 декабрендә 8356 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.09.2014 №490, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №400, 08.06.2017 №348, 17.11.2017 №809, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №885, 08.07.2019 №532, 03.09.2019 №665, 14.11.2019 №1017, 28.02.2020 №142, 09.07.2020 №491, 08.10.2020 №708, 24.03.2021 №154 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 17.11.2021 №849 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерык аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга»;

әлеге боерык белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган пособиеләр һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – бер бирелә торган пособие, айлык акчалата компенсация, дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

билгеләнгән тәртиптә вакцинация катлаулану аркасында инвалид дип танылган гражданнар, – айлык акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән очракта;

вакцинадан соң өзлегүләре булуы билгеләнгән гражданнар, – бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта;

вакцинадан соң өзлегү нәтиҗәсендә вафат булган очракта, гражданинның гаилә әгъзалары, – бер бирелә торган дәүләт пособиесен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә.

Бер тапкыр бирелә торган дәүләт пособиесен алу хокукына ия булган гаилә әгъзалары, «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясы нигезендә билгеләнә.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә күрсәтелә.»;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлекчәсенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) урнаштырылган.

1.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.2. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Үзәк бүлекчәсе урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекчәләрендә мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал).

Бердәм порталда «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы

белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;

3) Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлекчәсенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә дә) (mtsz@tatar.ru).»;

1.5 пунктта «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү.

2.2. Башкарма хакимият органы исеме

Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып айлык акчалата компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар тора – әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен, бер бирелә торган пособие – әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен (әлеге Регламентның 4 нче, 5 нче кушымталарындагы формалар буенча).

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Айлык акчалата компенсация, бер бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән башлап биш календарь көн эчендә кабул ителә.

2.4.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары аша документлар сорату зарурлыгы булган очракта, айлык акчалата компенсация, бер бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гаризаны һәм документларны тапшырган көннән башлап ун календарь көн эчендә кабул ителә.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата компенсация, бер бирелә торган пособие билгеләү турында кабул ителгән карар хакында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма формада почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта аша, телефонга смс-хәбәр итеп) хәбәр итү айлык акчалата компенсация, бер бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Айлык акчалата компенсация, бер бирелә торган дәүләт пособиесен билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, айлык акчалата компенсация, бер бирелә торган дәүләт пособиесен билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән башлап 5 көнлек чорда мөрәҗәгать итүчегә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, белдерү җибәрелә һәм гаризага теркәлгән документлар кире кайтарыла.

### 2.5. Закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен:

әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар түбәндәге документларны тапшыралар:

әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән форма буенча гариза;

вакцинадан соң өзлегү фактын билгеләү турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча гариза;

вакцинадан соң өзлегү фактын билгеләү турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

әлеге Регламентның 1.2 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча гариза;

вафат булу сәбәбе күрсәтелгән белешмә;

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән вафат булуны дәүләт

теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе, вафат булу очрагын теркәү чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан башкарылган очракта.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә һәм банкта ачылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.

2.5.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.4. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.6. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

2.5.7. Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

2.5.8. Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Вәкаләтле органнардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге белешмәләр алына:

шәхси счетның иминият номеры турында;

инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында.

2.6.2. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.Р120

2.6.3. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

2.6.4. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (документларны асылы буенча карамыйча кире кайтару) нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә аның законлы вәкиле булып тормаган затның яки ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләте бирелгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе.

Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру (җибәрү).

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча булмаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып дөрес булмаган (төгәл булмаган) белешмәләрдән торган документларны тапшыру тора.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында да белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте

**күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы**

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеүә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

белгечләр тарафыннан Регламент бозылуга бәйле прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмавы.

2.15.3. мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.15.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль законадагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 нче бүлектә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.4.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар рәсмиләштерү: әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен 4 нче кушымтага ярашлы форма буенча; әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча;»;

3.4.1 пунктчасының алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Үзәк бүлекчәсе белгече айлык акчалата компенсация, бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турында кабул ителгән карар турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә

баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, белдерү җибәрелә һәм гаризага теркәлгән документлар кире кайтарыла.

Әлеге пунктта каралган процедураларны үтәү срогы:

бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә белдерү һәм гаризага теркәлгән документларны кире җибәрү бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән башлап 5 көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

Бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләү турында кабул ителгән карар хакында белдерү җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән килгән очракта, бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләү турында карар күчермәсе мөрәҗәгать итүче килгән көнне бирелә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләү турында кабул ителгән карар хакында белдерү, мөрәҗәгать итүчегә бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата компенсация билгеләү турында карар күчермәсен бирү, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә белдерү һәм документлар җибәрү.»;

3.7.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

дәүләт хезмәте билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә: әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән гражданнар өчен – 4 нче кушымтага ярашлы форма буенча; әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән гражданнар өчен – әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча;»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.3 пунктның икенче абзацында «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) (https://www.gosuslugi.ru/)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый

төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә

_______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Гариза №____

_________ 20__ ел.

Мин,____________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адрес: ______________________________________________________,

_______________________________________________________________________,

(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)

эш итү нигезе:

_______________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

СНИЛС (алучыныкы) _________________

Билгеләвегезне сорыйм

_______________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

яши торган адрес: ______________________________________

_______________________________________________________________________.

(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

_______________________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

_______________________________________________________________________,

вакцинадан соңгы өзлегүләр барлыкка килгәндә айлык акчалата дәүләт компенсациясен.
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| т/с | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүне түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:
счетка күчерү юлы белән
______________________________________________________________________.
(гариза бирүче яисә аның законлы вәкиле тарафыннан кредит оешмасында социаль түләүләрне күчерү өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә ачылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлекчәсе аша ____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ___________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, риза:
почта адресы буенча язма формада ___________________________
_______________________________________телефонына смс-хәбәр итеп,
(телефон номеры)
электрон документ формасында
электрон почта адресы буенча ________________________________
(электрон почта адресы)
Мөрәҗәгать итүче:
______________________ ___________________________»__» ______________ 20__ ел
(мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
Гариза һәм документлар кабул ителде
______ 20__ ел. __________ _____________________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)
______________________________________________________________________.

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры ____
Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ____________ __________ ______________ ______________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Регламентка 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Регламентка 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Вакцинадан соңгы өзлегүләр барлыкка килгәндә айлык акчалата дәүләт компенсациясен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар

№_________ _________ 20__ ел.

_________________________________________________________________________.
вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгән айлык акчалата дәүләт компенсациясен билгеләү, билгеләүдән баш тарту) (кирәклесен күрсәтергә)

______________________________________________________________________________.

______________________________________________________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

__________________ сум күләмендә.

______________________________________________________________________________.

(баш тарткан очракта, сәбәбен күрсәтергә)

Түләү ысулы

______________________________________________________________________________.

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе

__________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)___________________ ________________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече

муниципаль районында (шәһәр округында) ___________________ ________________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):

әлеге адрес буенча язмача формада_____________________________________

_______________________________________________________________________

________________________________________телефонына смс-хәбәр итеп,

(телефон номеры)

электрон документ формасында

электрон почта адресы буенча _________________________________

(электрон почта адресы)

бүлек белгече ____________________________ ______________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе

___________________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Вакцинадан соңгы өзлегүләр барлыкка килгәндә бер тапкыр бирелә торган дәүләт пособиесен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар

№__________ «__» _________ 20__ ел.

______________________________________________________________________.
вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә бер бирелә торган дәүләт пособиесен (билгеләргә, билгеләүдән баш тартырга) (кирәклесен күрсәтергә)

______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
__________________ сум күләмендә.

______________________________________________________________________.
(баш тарткан очракта, сәбәбен күрсәтергә)
Түләү ысулы

______________________________________________________________________.
Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)
__________________ ________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм
(компенсацион түләүләр) үзәге»
ДКУ №___ бүлекчәсе белгече
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) __________________ ________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________
______________________________________________________________________
_______________________________________телефонына смс-хәбәр итеп,
(телефон номеры)
электрон документ формасында
электрон почта адресы буенча ________________________________
(электрон почта адресы)
бүлек белгече ___________________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)»;

Регламентка 6 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык

акчалата компенсацияләр билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 6 нчы
кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсенә

_________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта) тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес:
___________________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
___________________________________________________________________________.
___________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ________________________________________
вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата дәүләт компенсациясен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән ____________________________________________________.
(карар реквизитлары, бирелү датасы)

вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә бер бирелә торган дәүләт пособиесен, айлык акчалата дәүләт компенсациясен билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында мәгълүмат алуга риза ____________________________

(язма рәвештә, почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр итеп)
«__» _____________ 20__ ел. _______________________ _________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтада:
нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр
барлыкка килгәндә, гражданнарга
бер бирелә торган дәүләт
пособиеләрен һәм айлык акчалата
компенсацияләр билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентына
(белешмәлек) кушымта»;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга бер бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр.»